| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 31 октябре №6

**Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; хәрби хәрәкәт ветераннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, саны 18 яшькә җиткән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санының 30%ыннан арта алмый торган халыктан тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- С. Садри урамында юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
3) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- килешү буенча тракторчы хезмәтләре өчен түләү (территорияне коры-чүп үләннәреннән чабу, кардан чистарту, полосаларны минераллаштыру һәм башка эш төрләре);

-МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- чәчәк үсентеләре сатып алу;

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм Җирләү урыннарын карап тоту:

- коры һәм чүп үләннәрен чабу, карт, авария хәлендәге агачларны кисү, килешү буенча түләү;

- зират өчен чүп контейнерлары сатып алу.

5) ялны оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмасы хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 3 нче йорт буенча (балалар бакчасы бинасы), М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова